РЕСПУБЛИКА
ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ
КОМИТЕТ ИЗМИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
422052, Республика Татарстан,
Сабинский район,
с.Измя, ул. Школьная, 9
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ЭЗМӘ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

422052, Татарстан Республикасы,
Саба районы,
Эзмә авылы, Мәктәп урамы, 9 йорт
тел. (84362) 49-1-32, (84362) 49-1-22

e-mail: Izm.sab@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
27.02.2019 ел

КАРАР
№ 5

Татарстан Республикасы Саба муниципаль
районы Эзмә авыл җирлеге җирле
үзидарә органнарының муниципаль
хезмәткәрләре саны һәм аларның
хезмәт өчен түләүгә факттагы
чыгымнары турында квартал
саен мәгълүматлар бастырып
чыгару тәртибен раслау хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясы һәм Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге Уставы нигезендә Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты карар итте:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү буенча факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибен расларга. (1 нче кушымта ).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/izma бастырып чыгарырга.
3. Әлеге карар халыкка игълан ителгән көннән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Эзмә авыл җирлеге башлыгы: А.Р.Шәйхетдинов

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге башкарма комитетының 2019 елның 27 февралендә чыккан № 5 карарына 1 номерлы кушымта

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.

## I. Гомуми нигезләмәләр.

1.1 «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 52 статьясындагы 6 өлеше, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Эзмә авыл җирлеге Уставы нигезендә эшләнгән Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләү чыгымнарының факттагы күрсәткечләрен бастырып чыгару тәртибе (алга таба — Тәртип)

1.2. Тәртип Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен белешмәләр тапшыру, раслау һәм рәсми бастырып чыгару процедурасын билгели (алга таба — мәгълүматлар).

## II. Авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында мәгълүмат тапшыру тәртибе һәм составы.

2.1. Мәгълүматлар квартал саен җирле үзидарә органнары хезмәткәрләренең уртача саны, шул исәптән хисап чорында хезмәт эшчәнлеген гамәлгә ашырган Эзмә авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең исемлек буенча уртача саны турында, шулай ук хисап чорында хезмәт хакына исәпләнгән түләүләрне (акчалата эчтәлек) исәпкә алмыйча, хезмәт өчен түләү чыгымнарын тормышка ашыруга юнәлдерелгән бюджет ассигнованиеләре күләмен чагылдыралар.

2.2. Мәгълүматлар хисап чорыннан соң килүче айның 5 числосына кадәр әлеге Тәртипнең кушымтасы нигезендә бирелә.

2.3 Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты әлеге Тәртипнең кушымтасында бирелгән форма нигезендә мәгълүмат формалаштыра.

## III. Җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибе.

3.1. Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты тарафыннан отчет чорыннан соң килүче айның соңгы числосыннан да соңга калмыйча, мәгълүматларны раслау турында Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты карар проекты әзерләнә.

3.1.Эзмә авыл җирлеге башкарма комитеты карары белән расланган белешмәләр квартал саен хисап артыннан килүче икенче айның соңгы числосына кадәр Эзмә авыл җирлеге сайтында бастырылырга тиеш.

Эзмә авыл җирлеге җирле үзидарә органнарының муниципаль хезмәткәрләре саны һәм аларның хезмәтләре өчен түләүгә факттагы чыгымнары турында квартал саен мәгълүматлар бастырып чыгару тәртибенә кушымта

___________20__ел хисап чорына (беренче квартал, ярты ел, тугыз ай, ел))
Эзмәавылҗирлегежирлеүзидарәорганнарыныңмуниципальхезмәткәрләре саны
һәмаларныңхезмәтөчентүләүгәфакттагычыгымнарытурындамәгълүматлар

| Хезмәткәрләркатегориясе | Хисапчоры өчен, хезмәткәрләр саны | Хисап чорына хезмәт өчен түләүгә факттагы чыгымнар. (мең сумнарда) |
|---|---|---|
| Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Эзмә авыл җирлеге муниципаль берәмлеге хезмәткәрләре | | |
| шулисәптән: муниципальхезмәткәрләр | | |